КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 апрель г.Казань № 305

Казан шәһәре, Толстой урамы, 16 А йорт
адресы буенча урнашкан бина фасадына
мемориаль такта кую турында

Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасының (Иҗади берлек) Казан шәһәре, Толстой урамы, 16А йорт адресы буенча урнашкан йорт фасадына татар һәм рус телләрендәге түбәндәге текст белән Р.М.Миңнуллинга мемориаль такта кую турында тәкъдимне кабул итәргә:

«Бу йортта 2000 – 2020 елларда
Татарстан Республикасының
халык шагыйре,
дәүләт и җәмәгать эшлеклесе,
ТРның Г.Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты
Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин
яшәде

———

В этом доме в 2000 – 2020 гг.
жил народный поэт
Республики Татарстан,
государственный
и общественный деятель,
лауреат Государственной премии РТ им.Г.Тукая
Роберт Мугаллимович Миннуллин».

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә мемориаль тактаның балансста тотучысын билгеләүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин